Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

№641 Менделеевск ш. 11.11.2020

Менделеевск муниципаль районының
«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге
территориясендә бердәм җылылык белән
тәэмин итүче оешма статусын
«Газпром теплоэнерго Казань»
ҖЧҖенә бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, “Җылылык белән тәэмин итү турында” 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Җылылык белән тәэмин итү схемаларына таләпләр, аларны эшләү һәм раслау тәртибе турында” 2012 елның 22 октябрендәге 154 номерлы карары белән һәм «Татгазэнерго» ЯАҖен үзгәртеп коруга бәйле рәвештә «Газпром теплоэнерго Казан» ҖЧҖнә барлык хокукларны һәм бурычларын тапшырып үзгәртеп кору рәвешендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районының «Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖ «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма статусын бирергә.

2. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 07 октябрендәге 12 номерлы карарының 2 пунктын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http: //mendeleevsk.tatarstan.ru «Норматив документлар» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга https://pravo.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы С.В.Метальников